КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 11 декабрь г.Казань № 1132

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын әзерләү, аларны дәүләт теркәвенә алу һәм бастырып чыгару кагыйдәләрен раслау турында» 2002 ел, 18 июль, 426 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 19 май, 356 нчы, 2016 ел, 16 июнь, 408 нче, 2017 ел, 28 ноябрь, 920 нче, 2018 ел, 14 март, 152 нче, 2018 ел, 17 декабрь, 1153 нче, 2020 ел, 22 июль, 617 нче, 2022 ел, 23 июнь, 602 нче, 2023 ел, 26 гыйнвар, 49 нчы, 2023 ел, 10 июнь, 709 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын әзерләү, аларны дәүләт теркәвенә алу һәм бастырып чыгару кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

түбәндәге эчтәлекле 1.8 пункт өстәргә:

«1.8. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында Татарстан Республикасы законнары белән бүленгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын әзерләү һәм бастырып чыгару үзенчәлекләре билгеләнергә мөмкин.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру турында» 2023 ел, 29 декабрь, 1743 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында яңадан бүленгән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең территориаль планлаштыру һәм шәһәр төзелешен

зоналарга бүлү бердәм документын һәм территориаль планлаштыру документларын әзерләү һәм раслау вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибендә:

2.14 пунктка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Вәкаләтле органның генераль планны, схеманы раслау турындагы норматив хокукый акты Вәкаләтле орган җитәкчесе яисә аның урынбасары тарафыннан алар арасында вәкаләтләрне бүлү нигезендә имзалана.»;

3.13 пунктка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Вәкаләтле органның бердәм документны раслау, бердәм документка үзгәрешләр кертү турындагы норматив хокукый акты Вәкаләтле орган җитәкчесе яисә аның урынбасары тарафыннан алар арасында вәкаләтләрне бүлү нигезендә имзалана.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында яңадан бүленгән җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен әзерләү һәм раслау, җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт төренә рөхсәтләр һәм рөхсәт ителгән төзелешнең чикле параметрларыннан читкә тайпылуга, капиталь төзелеш объектын реконструкцияләүгә рөхсәтләр бирү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибенең 2.10 пунктына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Вәкаләтле органның җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турындагы норматив хокукый акты Вәкаләтле орган җитәкчесе яисә аның урынбасары тарафыннан алар арасында вәкаләтләрне бүлү нигезендә имзалана.»;

күрсәтелгән карар белән расланган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында яңадан бүленгән шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын әзерләү һәм раслау вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибенең 2.8 пунктының беренче абзацына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Вәкаләтле органның җирле нормативларны раслау турындагы норматив хокукый акты Вәкаләтле орган җитәкчесе яисә аның урынбасары тарафыннан алар арасында вәкаләтләрне бүлү нигезендә имзалана.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында яңадан бүленгән территорияне планлаштыру документларын әзерләүне һәм раслауны тәэмин итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибендә:

2.10 пунктка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Вәкаләтле органның территорияне планлаштыру документларын раслау турындагы норматив хокукый акты Вәкаләтле орган җитәкчесе яисә аның урынбасары тарафыннан алар арасында вәкаләтләрне бүлү нигезендә имзалана.»;

2.15 пунктта «раслана торган» сүзләрен «расланган» сүзенә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин